**МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.08.2014 № 1449

**г. Казань**

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфалары урынына калу коррупцион рисклар белән бәйле булган вазыйфаларның исемлеген раслау турында

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексының 64.1 маддәсенә, 2008 елның 25 декабреннән булган 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршылык күрсәтү турындагы» Федераль законга, 2012 елның 3 декабреннән булган 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфалары урынына калган һәм башка шәхесләрнең чыгымнарының керемнәренә туры килүләрен тикшерү турындагы» Федераль законга, 2009 елның 30 декабреннән булган УП-701 номерлы «Гражданнар Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларына билгеләнү вакытында һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре шушы вазыйфалар урынына калу вакытында үзләренең керемнәре, милекләре һәм милкенә бәйле булган йөкләмәләре турында мәгълүматларны, шулай ук үз хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милекләре һәм милекләренә бәйле булган йөкләмәләре турында мәгълүматларны тапшырырга тиеш булган шул вазыйфалар исемлеген раслау турындагы» Татарстан Республикасы Президенты указына, 2010 елның 30 сентябреннән булган УП-636 номерлы «Коррупциягә каршылык күрсәтү турындагы» Федераль законның аерым положениеләрен гамәлгә ашыру буенча чаралар турындагы» Татарстан Республикасы Президенты указына туры китереп б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфалары урынына калу

коррупцион рисклар белән бәйле булган вазыйфаларның теркәлгән исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга. Исемлеккә туры китереп, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфаларына билгеләнү вакытында, гражданнар үзләренең керемнәре, милекләре һәм милекләренә бәйле булган йөкләмәләре турында мәгълүматларны, шулай ук үз хатыннырының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милекләре һәм милекләренә бәйле булган йөкләмәләре турында мәгълүматларны тапшырырга тиеш, шулай ук Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфалары урынына калу вакытында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, милекләре һәм милекләренә бәйле булган йөкләмәләре турында мәгълүматларны, шулай ук үз хатыннырының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милекләре һәм милекләренә бәйле булган йөкләмәләре турында мәгълүматларны тапшырырга тиеш.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең Исемлеккә кертелгән вазыйфасы урынына калган гражданинның Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтеннән киткәннән соң ике ел эчендә хезмәт килешүе шартларында оешмада вазыйфалар урынына калырга хокукы бар һәм (яисә) дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәттә үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын көйләү буенча Министрлык комиссиясенең ризалыгы белән, әгәр дә шушы оешма белән дәүләт идарә итүенең аерым функцияләре Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең урындагы (хезмәттәге) йөкләмәләренә кергән булса, гражданлык-хокукый килешү (гражданлык-хокукый килешүләр) шартларында шул оешмада бер ай эчендә 100 мең сумнан артык бәясе булган эшләрне башкарырга (шул оешмага хезмәт күрсәтергә) хокукы бар;

Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең Исемлеккә кертелгән вазыйфалары урынына калган гражданин, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтеннән киткәннән соң ике ел эчендә, шушы боерыкның 2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән эшләрне башкару (хезмәт күрсәтү) өчен хезмәт яисә гражданлык-хокукый килешүләрне төзегән вакытта, эш бирүчегә үз хезмәтенең соңгы урыны турында мәгълүматны хәбәр итәргә тиеш;

Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең Исемлеккә кертелгән вазыйфалары урынына калган гражданинның Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтеннән киткәннән соң шушы боерыкның 2 пунктының өченче абзацында алдан исәпкә алынган таләпне үтәмәве эшләрне башкару (хезмәт күрсәтү) өчен күрсәтелгән гражданин белән төзелгән, шушы боерыкның 2 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән хезмәт яисә гражданлык-хокукый килешүенең тукталуына китерә .

3. Министрлыкның структур бүлекчәләренең җитәкчеләренә Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен кертелгән үзгәрешләр белән таныштырырга.

4. 14.01.2010 елгы 11нче номерлы «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы вазыйфаларының исемлеген раслау турындагы» Министрлык боерыгы көчен югалткан дип танырга.

5. Шушы боерыкның үтәлүен тикшерүне үз өстемдә калдырам.

Министр А.Ю. Вафин

В.С.Семенова,
(843) 231-79-15

08.08.2014 елгы 1449 номерлы
ТР ССМның боерыгына кушымта

**Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфалар урынына калу коррупцион рисклар белән бәйле булган вазыйфалары исемлеге**

1. «Җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр» (киңәшчеләр) категорияләренең вазыйфаларының бөтен группалары чикләрендә 18.10.2010 елгы УП-9 номерлы «Татарстан Республикасы Дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларының Реестры турындагы» Татарстан Республикасы Президенты Әмере белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларының Реестрына кертелгән, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфалары:

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары;

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының эшләре белән идарә итүче;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының идарәсе башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының бүлеге (идарә итү составына кермәгән) башлыгы;

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының ярдәмчесе.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфалар урынына калу коррупцион рисклар белән бәйле булган башка вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Стандартлар һәм медицина эшчәнлеге сыйфатын тикшерү идарәсенең медицина эшчәнлеге һәм медицина экспертизалары сыйфатын ведомство тикшерүе бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Стандартлар һәм медицина эшчәнлеге сыйфатын тикшерү идарәсенең стандартларны кертү һәм мониторинглау башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының югары технологияле медицина ярдәмен оештыру бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Дәвалау һәм профилактикалау ярдәме идарәсенең балаларга медицина ярдәмен күрсәтүне һәм бала табарга ярдәм итү хезмәтен оештыру бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Дәвалау һәм профилактикалау ярдәме идарәсенең дәвалау ярдәме бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Дәвалау һәм профилактикалау ярдәме идарәсенең профилактика ярдәме һәм сәламәтлек саклауны төзү бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Икътисадый анализлау һәм фаразлау идарәсенең бюджет чаралары буенча икътисадый анализлау бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Икътисадый анализлау һәм фаразлау идарәсенең ММЧ буенча икътисадый анализлау бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Икътисадый анализлау һәм фаразлау идарәсенең Дәүләт гарантияләре программасын исәпләү бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Медицина кадрларын аттестацияләү һәм аларның квалификацияләрен күтәрү секторының әйдәүче киңәшчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының бюджеттан тыш сәламәтлек саклау секторының әйдәүче киңәшчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация буенча идарәсенең дару тәэминәте белән идарә итү бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация буенча идарәсенең дару тәэминәте белән идарә итү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация буенча идарәсенең дару чаралары әйләнеше өлкәсендә тәртипкә салу бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация буенча идарәсенең дару чаралары әйләнеше өлкәсендә тәртипкә салу бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация буенча идарәсенең дәүләт заказын тәртипкә салу бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация буенча идарәсенең дәүләт заказын тәртипкә салу бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация буенча идарәсенең дәүләт заказын тәртипкә салу бүлегенең әйдәүче консультанты;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының медицина техникасы бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Лицензияләү буенча идарәсенең медицина эшчәнлеген лицензияләү буенча бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Лицензияләү буенча идарәсенең медицина эшчәнлеген лицензияләү буенча бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Лицензияләү буенча идарәсенең медицина эшчәнлеген лицензияләү буенча бүлегенең әйдәүче консультанты;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Лицензияләү буенча идарәсенең фармацевтик эшчәнлекне һәм наркотик матдәләр, психотроп матдәләр һәм прекурсларның әйләнеше белән бәйләнгән эшчәнлекне һәм наркотиклы үсемлекләрне үстерү буенча эшчәнлекне лицензияләү буенча бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Лицензияләү буенча идарәсенең фармацевтик эшчәнлекне һәм наркотик матдәләр, психотроп матдәләр һәм прекурсларның әйләнеше белән бәйләнгән эшчәнлекне һәм наркотиклы үсемлекләрне үстерү буенча эшчәнлекне лицензияләү буенча бүлегенең әйдәүче киңәшчесе.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсендә, вазыйфалар урынына калу коррупцион рисклар белән бәйле булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары:

Идарә җитәкчесе;

Идарә җитәкчесе урынбасары.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсендә, вазыйфалар урынына калу коррупцион рисклар белән бәйле булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары:

Идарә җитәкчесе;

Идарә җитәкчесе урынбасары.

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсендә, вазыйфалар урынына калу коррупцион рисклар белән бәйле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

Идарә җитәкчесе;

Идарә җитәкчесе урынбасары;

җитәкче урынбасары – өлкән халыкка дәвалау һәм профилактикалау ярдәмен күрсәтү бүлеге башлыгы;

балаларга медицина ярдәмен күрсәтүне һәм бала табарга ярдәм итү хезмәтен һәм демографик сәясәтне оештыру башлыгы;

сәламәтлек саклауның ресурслары белән оештыру-икътисадый идарә итү бүлеге башлыгы.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсендә, вазыйфалар урынына калу коррупцион рисклар белән бәйле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

Идарә җитәкчесе;

Идарә җитәкчесе урынбасары;

дәвалау ярдәмен күрсәтү бүлеге башлыгы;

икътисадый анализлау һәм финанслау бүлеге башлыгы.